РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«15» ноября 2018 г. г. Альметьевск № 259

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2017 елның 5 маендагы №182 «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы муниципаль милкендә булган җир кишәрлекләрен бүлү нәтиҗәсендә шәхси милектә булган җир кишәрлекләре мәйданын арттыру өчен түләү күләмен билгеләү тәртибе турында»гы карарына үзгәреш кертү турында

Россия Федерациясе Җир кодексының 2001 елның 25 октябрендәге №136-ФЗ 39.28 маддәсе 5 пунктының 3 пунктчасы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 3 августындагы №638 карары, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставы нигезендә

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2017 елның 5 маендагы №182 «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы муниципаль милкендә булган җир кишәрлекләрен бүлү нәтиҗәсендә шәхси милектә булган җир кишәрлекләре мәйданын арттыру өчен түләү күләмен билгеләү тәртибе турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карарның 1 нче кушымта 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Түләү күләме хосусый милектә булган җир кишәрлегенең кадастр бәясе арасындагы аерма, Әлмәт муниципаль районы муниципаль милкендәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү нәтиҗәсендә һәм шәхси милектә булган җир кишәрлегенең кадастр бәясе белән шәхси милектә булган җир кишәрлегенең

Зак. № 2652-100

кадастр бәясе арасындагы аерма буларак билгеләнә, әлеге Тәртипнең 4 пунктында каралган очрактан тыш.».

2. Район башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Әлмәт хәбәрләре» газетасында бастырырга, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Советының икътисадый үсеш, торак-коммуналь хуҗалык һәм муниципаль милек мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә (Закиров Ш.К.) йөкләргә.

Муниципаль район башлыгы А.Р. Хәйруллин